Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXII-2**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 23 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2012 елның 12 июлендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмә хакында” XVIII-12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында” 2014 елның 14 маендагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә, “Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен билгеләү тәртибен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 20 июлендәге 505 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 апрелендәге 214 номерлы карары чыгу белән бәйле рәвештә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 94 маддәсендәге 2,4 пунктлары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 1 өлешенең 22 пункты, “Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында” 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсе, Татарстан Республикасы Җир кодексының 12 маддәсендәге 3 пункты, Татарстан Республикасы Экология кодексының 142 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2012 елның 12 июлендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмә хакында” XVIII-12 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 27 сентябрендәге XXVIII-5 номерлы

карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 4 пунктны 3 пункт дип санарга;

1.2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турында Нигезләмәдә:

1 пунктта “саклау, файдалану һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә (алга таба - җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләре) түбәндәге җирләр керә:

1) махсус сакланылучы табигать территорияләре;

2) табигатьне саклау билгеләнешендәге;

3) рекреацион билгеләнештәге;

4) тарихи-мәдәни билгеләнештәге;

5) аеруча кыйммәтле җирләр.”;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү (алга таба - җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территория төзү) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба - Палата) карары белән әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән затлар тәкъдимнәре буенча гамәлгә ашырыла.”

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Палата, тәкъдим алган вакыттан алып утыз календарь көн эчендә җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләрне төзү кирәклеге турында гражданнарның, юридик затларның, иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең тәкъдимнәрен карый. Палата рәисе җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияне төзү турында материаллар әзерләү турында карар кабул итә яки әлеге пунктта билгеләнгән срок чикләрендә дәлилле баш тартуны белдерә.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга..

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев